**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 16 июнендәге 2055 номерлы карары**

**Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында»гы карарын, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында»гы карарын исәпкә алып, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, муниципаль хезмәтләрдән һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта) расларга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 7 декабрендәге 4288 номерлы «Муниципаль милектәге яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ

регламентын раслау турында»гы, 2021 елның 29 апрелендәге 1071 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 7 декабрендәге 4288 номерлы “Муниципаль милектәге яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы, 2015 елның 16 декабрендәге 4365 номерлы «Территориянең кадастр планында урнашкан җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау яисә территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен, хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык бирү хакында карар кабул итү буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарларын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 16 июнендәге
2055 номерлы карары белән
расланды

**Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

Регламент нигезләмәләре шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата да кулланыла.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик (шул исәптән шәхси эшмәкәрләр) һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүчеләр мәнфәгатьләрен гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләр тапшырылган затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүче вәкиле) яклый ала.

1.3. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт гариза бирүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш, алар «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

2.1. Муниципаль хезмәт атамасы – муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү.

2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органнар атамалары – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Комитет)

һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Идарә).

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Гариза бирүче җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын сорап мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе:

1) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар (5 номерлы кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар (хәбәрнамә) (7 номерлы кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

2.3.2. Гариза бирүче муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе:

1) территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык (6 номерлы кушымта);

2) муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проекты (аны әзерләү турында хәбәрнамә).

Муниципаль милектәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проекты Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4282 номерлы карары белән расланган форма буенча рәсмиләштерелә;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар (хәбәрнамә) (7 номерлы кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

2.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе (нәтиҗә турында хәбәрнамә) 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында»гы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) вазифаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган

электрон документ формасында гариза бирүченең Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.4. Комитетның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан имзаланган килешү проекты гариза бирүчегә кәгазь чыганакта Комитетта тапшырыла.

2.3.5. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гамәлдә булган вакыт дәвамында электрон документ рәвешендә яки электрон документның кәгазь чыганактагы нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты.

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты – гариза кергән көннән башлап 20 календарь көннән артмый.

2.4.2. Җир кишәрлегенең территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонада урнашуы турында мәгълүмат булса, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты 22 эш көненнән артмый.

2.4.3. Аның нигезендә җир кишәрлеге ясалырга тиешле җир кишәрлеген урнаштыру схемасы 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.5 статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булса, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты озайтылырга мөмкин, ләкин ул җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гариза кергән көннән алып 35 көннән дә артмаска тиеш.

2.4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгән көннән соң килә торган көннән башлап исәпләнә.

2.4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документны электрон документ рәвешендә җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнары белән каралмаган.

2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза биргәндә чиратта көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең муниципаль хезмәттән файдалану турындагы гаризасын теркәү вакыты.

2.7.1. Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан күпфункцияле үзәк аша тапшырылган гаризаны Орган күпфункцияле үзәктән алынган көнне билгеләнгән тәртиптә терки.

Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә гариза тапшырылган көнне күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры һәм электрон гариза бирү көне күрсәтелгән раслама бирелә.

2.7.2. Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталындагы, Бердәм порталдагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган, гаризаның теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килеп ирешкән мөрәҗәгать ялдан (бәйрәмнән) соң килә торган эш көнендә теркәлә.

2.7.3. Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза биргән көнне Органның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан гариза бирүчегә гаризаның кабул ителүен раслый торган теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән раслама тапшырыла.

2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр.

2.8.1. Муниципаль хезмәт янгын куркынычсызлыгы турындагы законнар таләпләре нигезендә янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

2.8.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә аларның муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарыннан каршылыксыз файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарыннан каршылыксыз файдалана алу мөмкинлеге (биналарга каршылыксыз керү/биналардан каршылыксыз чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү);

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштыру;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган

инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

5) инвалидларның күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен, аларның тормыш эшчәнлегендә чикләнгән булуларын исәпкә алып, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетеп һәм күреп була торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне, башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтын кулланып башкарылган билгеләр белән кабатлап бирү;

7) сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

8) озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»гы әмере белән билгеләнгән формада һәм тәртиптә бирелгән документ булганда, озатып йөрүче этне кертү.

2.8.3. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм 2.8.2 пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән, муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң кулланышка тапшырылган яки яңартылган, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

2.9. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу һәм аның сыйфат күрсәткечләре.

2.9.1. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

- документлар кабул ителә, бирелә торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

- мәгълүмат стендларында, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу;

- инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.

2.9.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын билгели торган күрсәткечләр:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү вакытын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

3) Комитет һәм Идарә хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

- муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә, гариза бирүченең күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән аралашуы, барлык кирәкле документлар белән гаризаны биргәндә, бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазь нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүченең вазифаи затлар белән бер тапкыр аралашу дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталны, Республика порталын, терминал җайланмаларын файдаланып бәяләргә хокуклы.

2.9.3. Хезмәтнең гариза бирүчеләр ихтыяҗларына туры килү-килмәвен тикшерү кире элемтәне анализлау нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 сентябрендәге 2786 номерлы «2025-2026 елларда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында клиентларның мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып эшләү стандартларын гамәлгә кертү турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә даими рәвештә гамәлгә ашырыла.

2.9.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталдагы яки Республика порталындагы шәхси кабинетында, Органда, күпфункцияле үзәктә алырга мөмкин.

2.9.5. Муниципаль хезмәт, гариза бирүченең яшәү урынына яки фактта яшәү (тору) урынына бәйсез рәвештә, аның сайлавы буенча теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

2.9.6. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу һәм аның сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының

рәсми порталында, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә карата башка, шул исәптән муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәктә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган таләпләр; муниципаль хезмәт турында мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирүгә карата таләпләр.

2.10.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче Органга шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә, аңа консультация бирелергә мөмкин.

2.10.3. Гариза тапшыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү, үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, экстерриториаль принципка нигезләнеп, гариза бирүче теләге буенча аның яшәү урынына яки фактта яшәү (тору) урынына (шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, физик затлар өчен) яисә урнашу урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә гамәлгә ашырыла.

2.10.4. Күпфункцияле үзәк тарафыннан гаризаны, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүне кире кагу турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә бирү, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган документларны кәгазь чыганакта бирү мөмкинлеге каралган.

2.10.6. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматтан файдаланырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон сурәтләре элегрәк 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Республика порталыннан,

Бердәм порталдан файдаланып бирергә;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларның үтәлеше һәм статусы турында мәгълүмат алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын Республика порталы, Бердәм портал ярдәмендә бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Республика порталы, Бердәм портал, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазифаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кабул ителгән карарларга һәм башкарылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә Органның, шулай ук андагы вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерергә.

Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла. Бу очракта гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә рәвештә бирү зарурияте юк.

2.10.7. Гаризаны формалаштырганда, гариза бирүчегә түбәндәге мөмкинлекләр тәэмин ителә:

1) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәсен алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүче тарафыннан гаризаның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазь чыганакта бастыру мөмкинлеге;

4) гаризаның электрон формасына элек кертелгән билгеләрне, шул исәптән гаризаның электрон формасына билгеләр кертүдә ялгышлар булганда һәм кабат кертү өчен әйләнеп кайтканда, кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта саклап калу мөмкинлеге;

5) гариза бирүче, Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында урнаштырылган, Бердәм порталда һәм Республика порталында бастырылган мәгълүматлардан файдаланып, белешмәләр кертә башлаганчы, гаризаның электрон формасында Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештәге юлларны тутыру мөмкинлеге;

6) электрон гариза формасын тутырганда, элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, теләсә кайсы этапка әйләнеп кайту мөмкинлеге.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, Орган телефоны, күпфункцияле үзәкнең контакт-үзәге телефоны аша башкарыла.

Гариза бирүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы буенча кабул итү өчен теләсә нинди буш көнгә һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер көнгә язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Гариза бирүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, гариза бирүчегә талон-расламаны бастырып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска, кабул итү көнен, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылып, гариза бирүче килмәгән очракта, билгеләнгән кабул итү вакытыннан соң 15 минут үткәч, алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче алдан язылу вакытыннан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләү һәм аутентификацияләү үтүдән, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен кирәкле вакыт аралыгын исәпләү өчен тиешле белешмәләрне тапшырудан тыш, гариза бирүчедән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.10.9. Мәгълүмат стендларында һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат Органның урнашу урыны, белешмә өчен телефон номерлары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

2.10.10. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.11. Җир кишәрлегенең урнашу схемасын электрон документ формасында әзерләү «“Пространство белешмәләренең илкүләм системасы”

бердәм цифрлы платформа» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

Регламентка 3 номерлы кушымтадагы таблицада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар түбәндәгеләргә бүленгән:

а) муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар;

б) муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

2.12. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кау өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итүне кире кагу турында карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

1) гариза вәкаләтләренә хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына тапшырылган;

2) гаризада хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 статьясының 2 пунктындагы таләпләр белән каралган мәгълүматлар юк яки гаризага Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 статьясының 3 пункты белән каралган документлар теркәлмәгән;

3) тапшырылган документлар (шәхесне таныклый торган документ; хезмәт күрсәтүне сорап, гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән затның вәкаләтләрен раслый торган документ) гариза бирүче хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдән чыккан;

4) тапшырылган документлардагы текстта Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар;

5) электрон формада тапшырылган документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар бар;

6) гариза һәм документлар электрон формада Бердәм порталдан файдаланмыйча яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше белән каралган таләпләр нигезендә имза формалаштыруны тәэмин итми торган башка программа тәэминатын кулланып тапшырылган;

7) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның гамәлдә булуын тану буенча 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы белән билгеләнгән шартларны үтәмәү очрагы ачыкланган;

8) гаризада һәм аңа теркәп бирелгән документларда каршылыклы мәгълүматлар бар;

9) документлар (вәкаләтләрне раслый торган документ, юридик затны чит дәүләттә теркәү турындагы документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны кабул итүне кире кагу турындагы карар формасы әлеге Регламентка 9 номерлы кушымтада китерелә.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар түбәндәге нигезләр буенча кабул ителә:

1) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гариза Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясының 1 пункты белән каралмаган очракларда тапшырылган;

2) яңадан бүлергә тәкъдим ителә торган җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясының 4 пунктында күрсәтелгән затларның хокуклары белән чикләнгән булса, күрсәтелгән затларның ризалыгы язма рәвештә тапшырылмаган;

3) хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милек хокукы барлыкка килә торган җир кишәрлегендә, сервитут, ачык сервитут нигезендә урнаштыру рөхсәт ителгән корылмадан (шул исәптән төзелеш эшләре тәмамланмаган корылмадан) яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясының 3 пункты нигезендә урнаштырылган объекттан тыш, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге, башка гражданнар яки юридик затлар милкендәге бина, корылма, төзелеш эшләре төгәлләнмәгән объект урнашачак;

4) территорияне ызанлау проекты яки җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге яки әйләнештән алынган яисә әйләнештә булуы чикләнгән җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү күз алдында тотыла (мондый яңадан бүлү Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 5 пунктның 7 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләре

булган территорияне ызанлау проекты нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш);

5) җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән ясау каралган;

6) территорияне ызанлау проекты яки җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм уздырылуы турындагы хәбәрнамә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукцион предметы булган яисә мондый җир кишәрлегенә карата аны бирүне алдан килештерү турында карар (гамәлдә булу вакыты тәмамланмаган) кабул ителгән җир кишәрлеген яңадан бүлү каралган;

7) җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм аларга карата җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза яки җир кишәрлеген бирү турында гариза тапшырылган һәм әлеге алдан килештерүне яисә бирүне кире кагу турында карар кабул ителмәгән җирләрне һәм җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән ясау каралган;

8) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милек хокукы барлыкка килә торган җир кишәрлеге мәйданы җир кишәрлекләренең билгеләнгән максималь чик үлчәмнәреннән артып китә;

9) җир кишәрлекләрен Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 1 һәм 4 пунктчалары нигезендә яңадан бүлү очракларыннан тыш, җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән каралган таләпләрне бозмыйча, мөстәкыйль җир кишәрлеге ясарга мөмкин булган җирләрне яңадан бүлү юлы белән ясау каралган;

10) хосусый милектәге җир кишәрлеге чикләре 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында»гы федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;

11) җир кишәрлегенең урнашу схемасы аның формасына, форматына яки аны әзерләүгә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясының 12 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килми;

12) ясалуы урнаштыру схемасы белән каралган җир кишәрлегенең урнашу урыны җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында элек кабул ителгән,

гамәлдә булу вакыты чыкмаган карар нигезендә ясала торган җир кишәрлегенең урнашу урыны белән тулысынча яки өлешчә туры килә;

13) җир кишәрлегенең урнашу схемасы ясала торган җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән билгеләнгән таләпләрне бозып эшләнгән;

14) җир кишәрлегенең урнашу схемасы территорияне планлаштыруның расланган проектына, җир төзелеше документларына, махсус саклана торган табигать территориясе турында нигезләмәгә туры килми;

15) федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, ясалуы җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән каралган җир кишәрлеге үзенә карата территорияне ызанлау проекты расланган территория чикләрендә урнашкан;

16) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турындагы гаризага теркәп бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы ясала торган җир кишәрлекләренә карата таләпләрне бозып эшләнгән яки территорияне планлаштыруның расланган проектына, җир төзелеше документларына, махсус саклана торган табигать территориясе турында нигезләмәгә туры килми;

17) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 статьясының 3 пункты белән каралган документлар тапшырылмаган;

18) хезмәттән файдалану турында гариза муниципаль милектәге (дәүләт милке чикләнмәгән) җир кишәрлеге белән яңадан бүлү күздә тотыла торган җир кишәрлеге милекчесе булып тормаган гариза бирүче тарафыннан тапшырылган;

19) ясалуы җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән каралган җир кишәрлеге үзенә карата территорияне ызанлау проекты расланган территория чикләрендә урнашкан;

20) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы белән каралган очракта дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә, мондый яңадан бүлү территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш, хосусый милектәге беренчел җир кишәрлегенең мәйданы бер мең квадрат метрдан артып китә;

21) хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы белән каралган нигез буенча яңадан бүлү нәтиҗәсендә элегрәк ясалган хосусый милектәге җир кишәрлеген күрсәтелгән нигез буенча яңадан бүлү күздә тотыла;

22) бүлү яки кушу нәтиҗәсендә әлеге пунктның 21 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән ясалган хосусый милектәге җир кишәрлеген Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы белән каралган нигез буенча яңадан бүлү күздә тотыла;

23) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерүне кире кагу турында хәбәрнамәсе;

24) җир кишәрлегенең һәм (яки) аңа чиктәш җир кишәрлекләренең чикләре, мәйданы, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре, аларны бушату, аларда урнашкан рөхсәтсез төзелгән яисә реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектларын сүтү турында суд бәхәсе. Суд карары законлы көченә кергәнче яки документларны тикшерү тәмамланганчы, хезмәт күрсәтү туктатып торыла;

25) эксплуатацияләүче оешмалар, шулай ук суны саклау, урман турындагы законнар өлкәсендә вәкаләтле органнар тарафыннан кире кагу очраклары булганда.

2.12.4. Гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр Регламентка 4 номерлы кушымтада китерелә.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакыты

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документларны кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

3) шәһәр төзелеше бәяләмәсен әзерләү өчен Идарәгә мәгълүмат җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү турында (хезмәт күрсәтүне кире кагу турында) карар кабул итү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документларны кабул итү.

3.2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша кабул итү.

Гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать итә һәм Регламентка

3 номерлы кушымта нигезендә документлар тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре:

- мөрәҗәгать предметын билгели;

- документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

- документларның Регламентка 3 номерлы кушымтада күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

- күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

- документлар кәгазь чыганакта тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканерлый;

- күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;

- тикшерү һәм имзалау өчен гариза бирүчегә тапшыра;

- имзалаганнан соң, имзаланган гаризаны күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасында сканерлый;

- электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон сурәтләрен күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эшнамә формалаштыра;

- имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

- гариза бирүчегә документларны кабул итү турында раслама бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар җыелмасы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре гариза бирүчедән кабул итеп алынган документлар җыелмасын Башкарма комитетка электрон формада (электрон эшнамәләр җыелмасы составында) гариза бирүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән алып бер эш көне эчендә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Башкарма комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар җыелмасы (электрон эшнамә).

3.2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада кабул итү.

Гаризаны электрон формада Республика порталы аша тапшыру өчен гариза бирүче:

- авторизация уза;

- электрон гариза формасын ача;

- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

- электрон формадагы документларны яки документларның электрон сурәтләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

- электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу, килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

- хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга куя);

- электрон гаризаны 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалый;

- тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

- электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы аша Башкарма комитетка җибәрелгән электрон эшнамә.

3.2.3. Органда документлар җыелмасын карап тикшерү.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат (хезмәткәр) – Башкарма комитет хезмәткәре (алга таба – документлар кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат).

Карап тикшерү өчен документлар кергәннән соң, документлар кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат:

- гаризага эшнамәләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, бу Республика порталындагы шәхси кабинетта чагыла;

- килеп ирешкән электрон эшнамәләрне, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон сурәтләрен өйрәнә;

- документлар җыелмасының тулы, электрон сурәтләренең укылышлы булу-булмавын тикшерә;

- Бердәм порталга кереп, электрон имзаның гамәлдә булу шартларының үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан документларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон сурәтләре тапшырылган очракта);

- гариза бирүче тарафыннан тапшырылган схеманы Комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасына кертә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның гамәлдә булу шартлары үтәлмәве ачыкланса, кире кагу турында карар проекты аны кабул итү өчен нигез булып торган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турында карар проекты, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләр бозылу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрдә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләрне үз эченә алган, билгеләнгән таләпләрне бозып тутырылган документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исемнәре турында мәгълүмат булырга тиеш), электрон документлар әйләнеше системасы аша билгеләнгән тәртиптә килештерүгә җибәрелә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре: карап тикшерү өчен кабул ителгән гариза яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турында карар проекты.

3.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек.

3.3.1. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати мөрәҗәгатьләр җибәрү зарур:

1) «Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында мәгълүмат)» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә җибәрелә. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте соратыла торган белешмәләрне ведомствоара мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча юллый;

2) «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә җибәрелә. Федераль салым хезмәте соратыла торган белешмәләрне ведомствоара мөрәҗәгать җибәрелгән көннән алып биш эш көненнән дә

артмаган вакыт эчендә юллый. Мондый мөрәҗәгать хезмәттән файдалануны сорап юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә җибәрелә. Федераль салым хезмәте соратыла торган белешмәләрне ведомствоара мөрәҗәгать җибәрелгән көннән алып биш эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә юллый. Мондый мөрәҗәгать хезмәттән файдалануны сорап шәхси эшмәкәр мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати мөрәҗәгатьләр җибәрү зарур:

1) «Гариза бирүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» мәгълүмати мөрәҗәгате. Хезмәттән файдалануны сорап, гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать «Гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры» сервисы яки «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә бер эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә ике эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла;

3) «Адресация объектына бирелгән адрес турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать «Федераль мәгълүмат адреслар системасы» сервисы ярдәмендә ике эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла;

4) «Сорала торган җир кишәрлегендә корылмалар булу-булмау турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать «Электрон хуҗалык китабы» сервисы ярдәмендә ике эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә гамәлгә ашырыла;

5) «Җир җишәрлеген бирү өчен чикләүләр булу яки булмау турында бәяләмә (шул исәптән территориаль зона, кызыл линияләр чикләре, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары турында)» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмат Идарәдән биш эш көненнән арттырмаган вакыт эчендә соратыла;

6) «Су объектлары чикләре турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгыннан, «Средволгаводхоз» су

хуҗалыгы федераль дәүләт учреждениесеннән (гамәлдәге законнар белән билгеләнгән очракларда) биш эш көненнән арттырмаган вакыт эчендә соратыла;

7) «Урман участоклары чикләре турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгыннан биш эш көненнән арттырмаган вакыт эчендә соратыла;

8) «Җир кишәрлегенең сак зоналарында булу-булмавы турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мәгълүмати мөрәҗәгать «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән, Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалыннан, башка эксплуатацияләүче оешмалардан биш эш көненнән арттырмаган вакыт эчендә соратыла;

9) «Мәдәни әһәмияткә ия объект турында белешмәләр» мәгълүмати мөрәҗәгате. Күрсәтелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан соратыла.

3.4. Шәһәр төзелеше бәяләмәсен әзерләү өчен Идарәгә мәгълүмат юллау.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат – Идарәнең вәкаләтле бүлеге белгече (алга таба – бәяләмә әзерләү өчен җаваплы вазифаи зат).

Бәяләмә әзерләү өчен җаваплы вазифаи зат муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен Регламентның 2.12.3 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу яисә булмауга тикшерү нәтиҗәсен үз эченә алган шәһәр төзелеше бәяләмәсе проектын әзерли; әзерләнгән проектны билгеләнгән тәртиптә электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә килештерүгә җибәрә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: имзаланган шәһәр төзелеше бәяләмәсе.

Шәһәр төзелеше бәяләмәсе тискәре булган очракта, административ процедураларны башкаруның максималь вакыты өч эш көнен тәшкил итә.

Шәһәр төзелеше бәяләмәсе уңай булган очракта яки башка чикләрдә әзерләнсә, документ Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2022 елның 19 апрелендәге П/0148 номерлы әмере белән расланган форма буенча территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын әзерләү өчен вәкаләтле белгечкә җибәрелә. Башкару вакыты – бер көн.

Әлеге пунктта күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь вакыты дүрт эш көнен тәшкил итә.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне (хезмәт күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документның административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат тарафыннан алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазифаи зат – Башкарма комитет белгече (алга таба – документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы белгеч).

Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы белгеч:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар белән эшләү буенча ярдәмче системасында, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

- гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документ имзаланган көнне башкарыла. Техник мөмкинлекләр булганда, процедуралар автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне мәгълүмат системаларында урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү (хезмәт күрсәтүне кире кагу) турында карар кабул итү.

3.6.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр Регламентның 2.12.3 пунктында күрсәтелгән һәм әлеге Регламентка 4 номерлы кушымтада китерелә.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү (хезмәт күрсәтүне кире кагу) турында карар кабул итү вакыты әлеге Регламентның 2.4 пунктында күрсәтелгән.

3.6.3. Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен гариза бирүче җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү хакындагы гариза (10 номерлы кушымта) белән Комитетка мөрәҗәгать итә.

Сорала торган җир кишәрлеге расланган схема нигезендә ясалган очракта, Комитет белгече җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проектының имзаланган нөсхәләрен гариза бирүчегә (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән

затка) имзалау өчен бирә. Гариза бирүче, килешүне алган көннән башлап утыз көннән дә соңга калмыйча, аны имзаларга тиеш.

Гариза бирүче килешү проекты нөсхәләрен имзалый, Комитетка кире кайтара һәм әлеге килешүдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына акча (җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүдә күрсәтелгән сумманы) күчерә, түләүне раслый торган документны Комитетка тапшыра.

Гариза бирүче килешүне имзалаганнан һәм имзаланган килешүне Комитетка тапшырганнан соң, Комитет белгече шартнамәдә гариза бирүченең имзасы һәм мөһере булу-булмауны, җир кишәрлеге бәясенең түләнүен һәм күрсәтелгән акчаның бюджетка күчерелүен тикшерә.

Акча күчү турында мәгълүмат алгач, Комитет белгече:

- килешүнең барлык нөсхәләренә дата куя, мөһер суга;

- 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында»гы федераль законның 19 статьясы нигезендә килешүне, дәүләт теркәвенә алу өчен, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрә;

- гариза бирүчегә (аның вәкиленә) теркәүче орган тарафыннан хокукның дәүләт теркәвенә алынуы турында (яки хокукны дәүләт теркәвенә алуны туктатып тору, кире кагу турында) хәбәр итә;

- шартнамәләр бирү журналында имза куйдырып, килешү нөсхәсен(- ләрен) гариза бирүчегә тапшыра.

Гариза бирүче тарафыннан килешүне имзалауны көтү вакыты, акчаларны күчерү турында мәгълүматны көтү вакыты һәм килешүне теркәү белән бәйле гамәлләргә сарыф ителгән вакыт муниципаль хезмәт күрсәтү вакытына керми.

Килешүне имзалау һәм бирү гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе.

1) гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткән очракта, Башкарма комитет хезмәткәре гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне Башкарма комитетның эш регламентында билгеләнгән вакыт эчендә чират тәртибендә башкарыла;

2) гариза бирүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу өчен Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган, Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи затының

көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документның электрон сурәте гариза бирүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (хезмәт күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документ Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документны җибәрү (бирү).

3.8. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка түбәндәгеләрне җибәрә:

- техник хатаны төзәтү турында гариза (11 номерлы кушымта);

- гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документ;

- техник хата булуны дәлилли торган юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта яки Бердәм портал, Республика порталы яисә күпфункцияле үзәк аша бирелә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, беркетелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазифаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазифаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазифаи зат документларны карап тикшерә һәм, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатыннан, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып, шәхсән үзенә имза куйдырып, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) тапшыра яки гариза бирүче адресына почта (электрон почта) аша, техник хаталы документның төп нөсхәсен Башкарма комитетка тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге булу турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

3.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документның дубликатын бирү.

3.9.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документның дубликатын алу максатыннан дубликат бирү турында әлеге Регламентка 12 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча гариза тапшырыла.

Документ дубликатын бирү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта яки Бердәм портал, Республика порталы яисә күпфункцияле үзәк аша тапшырыла.

3.9.2. 3.9.1 пунктта күрсәтелгән гаризаны теркәү гариза вәкаләтле органга яки күпфункцияле үзәккә кергән көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазифаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.9.3. Вәкаләтле органның вазифаи заты 3.9.1 пунктта күрсәтелгән гаризаны теркәгән көненнән алып җиде эш көне эчендә элегрәк бирелгән документта күрсәтелгән шул ук теркәү номеры белән документның дубликатын яки документ дубликатын бирүне кире кагу турында карарны рәсмиләштерә һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Элегрәк гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документ вәкаләтле органның вазифаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында бирелгән булса, күрсәтелгән документ гариза бирүчегә документ дубликаты сыйфатында кабат тапшырыла.

3.9.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документ дубликаты яки әлеге Регламентка 12 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча документ дубликатын бирүне кире кагу турында карар гариза бирүчегә дубликат бирү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән дубликат бирү турында гариза кергән көненнән алып җиде эш көне эчендә җибәрелә.

3.9.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документ дубликатын бирүне кире кагу өчен нигезләр:

- гариза бирүче әлеге Регламентның I бүлегендәге 1.2 пунктында күрсәтелгән затлар даирәсенә туры килми;

- тапшырылган документлар мөрәҗәгать итү көненә гамәлдән чыккан (шәхесне таныклый торган документ; муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән затның вәкаләтләрен раслый торган документ);

- тапшырылган документлардагы текстта чистартулар һәм төзәтүләр бар;

- электрон рәвештә тапшырылган документлар документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган дәрәҗәдә зарарланган.

3.10. Гариза бирүченең муниципаль хезмәттән файдалану турында гаризасын карап тикшермичә калдыру тәртибе.

3.10.1. Гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) вәкаләтле органга яки күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәттән файдалану турында гаризаны карап тикшермичә калдыру хакындагы гариза белән әлеге Регламентка 13 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча шәхсән мөрәҗәгать итә.

3.10.2. Гаризаны карап тикшермичә калдыру өчен нигезләр ачыкланган очракта, вәкаләтле орган 3.10.1 пунктта күрсәтелгән гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә гариза бирүчегә гаризаны карап тикшермичә калдыру турында хәбәрнамә юллый.

3.10.3. Гариза бирүченең гаризасын карап тикшермичә калдыру гариза бирүчегә шул ук муниципаль хезмәттән файдалануны сорап кабат мөрәҗәгать итү өчен тоткарлык була алмый.

3.10.4. Гариза бирүченең әлеге Регламентның I бүлегендәге 1.2 пунктында күрсәтелгән затлар даирәсенә туры килмәве муниципаль хезмәттән файдалану турында гаризаны карап тикшермичә калдыруны кире кагу өчен нигез булып тора.

## IV. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карап тикшерү статусы үзгәрү хакында хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлек булганда, гариза бирүчегә Регламент белән билгеләнгән хезмәт күрсәтү турында гаризаның статусы үзгәрү хакында (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү; гаризаны һәм документлар җыелмасын карап тикшерү; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук хезмәт күрсәтүнең әлеге этабында гариза бирүче тарафыннан башкарылырга тиешле

адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсен кулланып хәбәр ителә:

- СМС-хәбәр;
- Бердәм портал аша;
- Республика порталы аша;
- башка сервислардан һәм ысуллардан файдаланып (булган очракта).

---

Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки)
җир кишәрлекләрен һәм хосусый
милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
1 номерлы кушымта

**Шартлы билгеләр һәм кыскартылмалар исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) – Реестр;
4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән эш йөртүче «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Комитет) һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Идарә) – Башкарма комитет (Орган);
5. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе – күпфункцияле үзәк;
6. Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки)
җир кишәрлекләрен һәм хосусый
милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 номерлы кушымта

## Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүченең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында алга таба килешү төзү өчен территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар | Физик зат | 1А |
| | | Юридик зат | 2А |
| | | Шәхси эшмәкәр | 3А |
| | | Гариза бирүче вәкиле | 4А |
| 2 | Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган физик затлар | 1Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган юридик затлар | 2Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган шәхси эшмәкәрләр | 3Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган гариза бирүче вәкилләре | 4Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган физик затлар | 5Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган юридик затлар | 6Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган шәхси эшмәкәрләр | 7Б |
| | | Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыруның расланган схемасы булган гариза бирүче вәкилләре | 8Б |

Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 номерлы кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен**
**кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Иденти-фикатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Гариза | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| 2 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Шәхесне таныклый торган документ | Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| 3 | 4А, 4Б | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| 4 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Җир кишәрлекләрен яңадан бүлүгә җирдән файдаланучыларның, җир хуҗаларының, арендага алучыларның язмача ризалыгы | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| 5 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Җир кишәрлекләрен яңадан бүлүгә залогка алучыларның язмача ризалыгы | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| 6 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Җир кишәрлегенең урнашу схемасы | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар | | | |
| 1 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Гариза бирүченең җир кишәрлегенә карата хокукларын билгеле яки хокукларын раслый торган документларның күчермәләре | Бердәм портал, Республика порталы, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |
| 2 | 1А-4А,<br>1Б-8Б | Юридик затны чит ил законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очракта, мәҗбүри тапшырыла) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк |

Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 номерлы кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу, гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр | | |
| 1 | 1А-8Б | Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гариза Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясының 1 пункты белән каралмаган очракларда тапшырылган |
| 2 | 1А-8Б | Яңадан бүлергә тәкъдим ителә торган җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясының 4 пунктында күрсәтелгән затларның хокуклары белән чикләнгән булса, күрсәтелгән затларның ризалыгы язма рәвештә тапшырылмаган |
| 3 | 1А-8Б | Хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милек хокукы барлыкка килә торган җир кишәрлегендә, сервитут, ачык сервитут нигезендә урнаштыру рөхсәт ителгән корылмадан (шул исәптән төзелеш эшләре тәмамланмаган корылмадан) яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясының 3 пункты нигезендә урнаштырылган объекттан тыш, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге, башка граждannар яки юридик затлар милкендәге бина, корылма, төзелеш эшләре төгәлләнмәгән объект урнашачак |
| 4 | 1А-8Б | Территорияне ызанлау проекты яки җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль |

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| | | милектәге яки әйләнештән алынган яисә әйләнештә булуы чикләнгән җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү күз алдында тотыла (мондый яңадан бүлү Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 5 пунктның 7 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләре булган территорияне ызанлау проекты нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш) |
| 5 | 1А-8Б | Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән ясау каралган |
| 6 | 1А-8Б | Территорияне ызанлау проекты яки җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм уздырылуы турындагы хәбәрнамә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукцион предметы булган яисә мондый җир кишәрлегенә карата аны бирүне алдан килештерү турында карар (гамәлдә булу вакыты тәмамланмаган) кабул ителгән җир кишәрлеген яңадан бүлү каралган |
| 7 | 1А-8Б | Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм аларга карата җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза яки җир кишәрлеген бирү турында гариза тапшырылган һәм әлеге алдан килештерүне яисә бирүне кире кагу турында карар кабул ителмәгән җирләрне һәм җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән ясау каралган |
| 8 | 1А-8Б | Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милек хокукы барлыкка килә торган җир кишәрлеге мәйданы җир кишәрлекләренең билгеләнгән максималь чик үлчәмнәреннән артып китә |

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| 9 | 1А-8Б | Җир кишәрлекләрен Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 1 һәм 4 пунктчалары нигезендә яңадан бүлү очракларыннан тыш, җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән каралган таләпләрне бозмыйча, мөстәкыйль җир кишәрлеге ясарга мөмкин булган җирләрне яңадан бүлү юлы белән ясау каралган |
| 10 | 1А-8Б | Хосусый милектәге җир кишәрлеге чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында»гы федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш |
| 11 | 1А-8Б | Җир кишәрлегенең урнашу схемасы аның формасына, форматына яки аны әзерләүгә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясының 12 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килми |
| 12 | 1А-8Б | Ясалуы урнаштыру схемасы белән каралган җир кишәрлегенең урнашу урыны җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында элек кабул ителгән, гамәлдә булу вакыты чыкмаган карар нигезендә ясала торган җир кишәрлегенең урнашу урыны белән тулысынча яки өлешчә туры килә |
| 13 | 1А-8Б | Җир кишәрлегенең урнашу схемасы ясала торган җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән билгеләнгән таләпләрне бозып эшләнгән |
| 14 | 1А-8Б | Җир кишәрлегенең урнашу схемасы территорияне планлаштыруның расланган проектына, җир төзелеше документларына, махсус саклана торган табигать территориясе турында нигезләмәгә туры килми |
| 15 | 1А-8Б | Федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, ясалуы җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән каралган җир кишәрлеге үзенә карата территорияне ызанлау проекты расланган территория чикләрендә урнашкан |

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| 16 | 1А-8Б | Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турындагы гаризага теркәп бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы ясала торган җир кишәрлекләренә карата таләпләрне бозып эшләнгән яки территорияне планлаштыруның расланган проектына, җир төзелеше документларына, махсус саклана торган табигать территориясе турында нигезләмәгә туры килми |
| 17 | 1Б-8Б | Хезмәттән файдалану турында гариза муниципаль милектәге (дәүләт милке чикләнмәгән) җир кишәрлеге белән яңадан бүлү күздә тотыла торган җир кишәрлеге милекчесе булып тормаган гариза бирүче тарафыннан тапшырылган |
| 18 | 1А-4А | Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 статьясының 3 пункты белән каралган документлар тапшырылмаган |
| 19 | 1Б-8Б | Ясалуы җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән каралган җир кишәрлеге үзенә карата территорияне ызанлау проекты расланган территория чикләрендә урнашкан |
| 20 | 1А-8Б | Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы белән каралган очракта дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә, мондый яңадан бүлү территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш, хосусый милектәге беренчел җир кишәрлегенең мәйданы бер мең квадрат метрдан артып китә |
| 21 | 1А-8Б | Хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы белән каралган нигез буенча яңадан бүлү нәтиҗәсендә элегрәк ясалган хосусый милектәге җир кишәрлеген күрсәтелгән нигез буенча яңадан бүлү күздә тотыла |

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| 22 | 1А-8Б | Бүлү яки кушу нәтиҗәсендә әлеге пунктның 21 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән ясалган хосусый милектәге җир кишәрлеген Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы белән каралган нигез буенча яңадан бүлү күздә тотыла |
| 23 | 1А-4А | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерүне кире кагу турында хәбәрнамәсе |
| 24 | 1А-8Б | Җир кишәрлегенең һәм (яки) аңа чиктәш җир кишәрлекләренең чикләре, мәйданы, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре, аларны бушату, аларда урнашкан рөхсәтсез төзелгән яисә реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектларын сүтү турында суд бәхәсе. Суд карары законлы көченә кергәнче яки документларны тикшерү тәмамланганчы, хезмәт күрсәтү туктатып торыла |
| 25 | 1А-4А | Эксплуатацияләүче оешмалар, шулай ук суны саклау, урман турындагы законнар өлкәсендә вәкаләтле органнар тарафыннан кире кагу очраклары булганда |
| Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр | | |
| 1 | 1А-4А, 1Б-8Б | Гариза вәкаләтләренә хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына тапшырылган |
| 2 | 1Б-8Б | Гаризада хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 статьясының 2 пунктындагы таләпләр белән каралган мәгълүматлар юк |
| 3 | 1А-4А, 1Б-8Б | Тапшырылган документлар (шәхесне таныклый торган документ; хезмәт күрсәтүне сорап, гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән затның вәкаләтләрен раслый торган документ) гариза бирүче хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдән чыккан |

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең аңлатмалары, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| 4 | 1А-4А, 1Б-8Б | Тапшырылган документлардагы текстта Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар |
| 5 | 1А-4А, 1Б-8Б | Электрон формада тапшырылган документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар бар |
| 6 | 1А-4А, 1Б-8Б | Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар электрон рәвештә билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылган |
| 7 | 1А-4А, 1Б-8Б | Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның гамәлдә булуын тану буенча «Электрон имза турында»гы федераль законының 11 статьясы белән билгеләнгән шартларны үтәмәү очрагы ачыкланган |
| 8 | 1А-4А, 1Б-8Б | Гаризада һәм аңа теркәп бирелгән документларда каршылыклы мәгълүматлар бар |
| 9 | 1А-4А, 1Б-8Б | Документлар (вәкаләтләрне раслый торган документ, юридик затны чит дәүләттә теркәү турындагы документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган |

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
5 номерлы кушымта
(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

**Территориянең кадастр планында**
**җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында**
**_____ елның _____________ _____ номерлы**
**КАРАР**

_______________ кадастр кварталында урнашкан, мәйданы ____________ булган җир кишәрлеген территориянең кадастр планында урнаштыру схемасын раслау турында ______ елның _____________ ____номерлы гаризаны (гариза бирүче – ____________________________) карап тикшергәннән соң, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10, 39.11 статьяларына, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында»гы әмеренә таянып, ___________________________________________ нигезендә

КАРАР КАБУЛ ИТЕЛДЕ:

1. Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен территориянең кадастр планында түбәндәге җир кишәрлеген урнаштыру схемасын расларга: мәйданы _______ кв.м, ____________________________ адресы буенча урнашкан, җирләр категориясе – _________________________, рөхсәт ителгән файдалану төре – _________________________.

2. Гариза бирүчегә –________________ кадастр эшләрен башкаруны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген закон белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт кадастр исәбенә куюны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән файдалануга түбәндәге чикләүләрне билгеләргә (чикләүләр булган очракта): ________________________________________________________.

4. Әлеге карарның гамәлдә булу вакыты – ике ел.

| ______________________________ | ___________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (карар кабул итүче органның вәкаләтле заты вазифасы) | (имза) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
6 номерлы кушымта
(Форма)

**Территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә**
**җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык**

_____ елның __________________ №_____

Сезнең ______ елның __________________ ____ номерлы мөрәҗәгатегезгә
__________________________________________________________________________,
(органның атамасы)
Россия Федерациясе Җир кодексына, 2014 елның 23 июнендәге 171-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында»гы әмеренә таянып, хосусый милектәге _____________ кадастр номерлы җир кишәрлеген һәм муниципаль милектәге/дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне/җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык белдерелүе турында хәбәр итә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 статьясының 11 пункты нигезендә Сезгә, яңадан бүлү нәтиҗәсендә ясалачак җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә алу максатыннан, кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итәргә һәм дәүләт кадастр исәбенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк.

| Электрон имза турында мәгълүмат |
| --- |
| |

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
7 номерлы кушымта
(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

Кемгә: ________________________________________
________________________________________
(гражданнар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен –
фамилиясе, исеме, атасының исеме;
юридик затлар өчен – оешманың тулы атамасы)

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында**
**_____ елның __________________ _____ номерлы**
**КАРАР**

_____ елның __________________ _____ номерлы гаризаны (гариза бирүче: ___________________________) карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәгеләргә нигезләнеп, хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар кабул ителде: ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

Кире кагу сәбәпләрен аңлату: ______________________________________________
______________________________________________________________________________.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ______________________________________________
______________________________________________________________________________.

Күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәннән соң, Сез хезмәт күрсәтү турында гариза белән вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагуга карата шикаять аны вәкаләтле органга җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында мәгълүмат |
|---|

| ___________________________ | ______________ | ___________________________ |
|---|---|---|
| (карар кабул итүче органның вәкаләтле заты вазифасы) | (имза) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
8 номерлы кушымта
(Форма)

Юридик затлар өчен

________________________________________
(җирле үзидарә органы атамасы)

________________________________________

________________________________________
(оешманың тулы атамасы һәм
оештыру-хокукый формасы)
исеменнән эш йортүче

________________________________________

________________________________________
(җитәкченең яки башка вәкаләтле затның
фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ:

________________________________________
(документ төре)

________________________________________
(сериясе, номеры)

________________________________________
(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)
Юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр:

Төп дәүләт теркәве номеры________________

________________________________________

Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры ________________________________________

Урнашу урыны адресы:

________________________________________

________________________________________

Элемтә өчен мәгълүмат:

1 телефон номеры ______________________

2 телефон номеры ______________________

электрон почта ___________________________

Физик затлар һәм
шәхси эшмәкәрләр өчен

Фамилиясе, исеме, атасының исеме ________
_______________________________________________
Шәхесне таныклый торган документ:
_______________________________________________
(документ төре)
_______________________________________________
(сериясе, номеры)
_______________________________________________
(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Дәүләт теркәве номеры (шәхси эшмәкәрләр өчен)
_______________________________________________

Теркәлү адресы:
_______________________________________________
_______________________________________________

Ышанычнамә буенча вәкил яки законлы вәкил:
_______________________________________________
Фамилиясе, исеме, атасының исеме
_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________
Шәхесне таныклый торган документ:
_______________________________________________
_______________________________________________
(документ төре)
_______________________________________________
(сериясе, номеры)
_______________________________________________
(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Вәкаләтләрне раслый торган документ реквизитлары:
_______________________________________________
_______________________________________________

Теркәлү адресы:
_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________

Элемтә өчен мәгълүмат:
1 телефон номеры ______________________________
2 телефон номеры ______________________________
электрон почта ______________________________

ГАРИЗА

Кадастр номеры ____________________, мәйданы ________ кв.м, җирләр категориясе (булган очракта) __________________________, рөхсәт ителгән файдалану төре (булган очракта) ________________________ булган җир кишәрлеген яңадан бүлүегезне сорыйм, ясала торган җир кишәрлеге мәйданы ____ кв.м.

Территорияне ызанлауның расланган проекты реквизитлары (булган очракта): __________________________________________________________.

Кушымта:

1. _______________________________________
2. _______________________________________
3. _______________________________________

| |
|---|
| Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен миңа түбәндәге ысул белән бирүегезне (җибәрүегезне) сорыйм: |
| ☐ электрон рәвештә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка; |
| ☐ Башкарма комитетта; |
| ☐ күпфункцияле үзәктә |

Гариза бирүче имзасы _____________________
(имзаның аңлатмасы)

Дата ______________________________________

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
9 номерлы кушымта
(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны
кабул итүне кире кагу турында карар

_______________________________________________________________

(гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүче юридик зат атамасы)

мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, ______ елның _________________ _____ номерлы _________________________________________________________ турында гариза,

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________нигезендә

тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәгеләргә таянып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турында карар кабул ителде:

1. _____________________________________________________________

2. _____________________________________________________________

Күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәннән соң, Сез хезмәт күрсәтү турында гариза белән вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге кире кагуга карата шикаять аны вәкаләтле органга җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә бирелергә мөмкин.

Вазифаи зат
(фамилиясе, исеме, атасының исем) ______________________________

(органның имзалаучы вазифаи заты имзасы)

| Электрон имза турында мәгълүмат |
| --- |

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
10 номерлы кушымта
(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисенә

_______________________________________

*Кемнән:* ______________________________

_______________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

паспорт: сериясе________ номеры __________

кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән:_______

_______________________________________.

Адрес: индекс _________________________,

_____________ шәһәре, _____________ урамы,

_______ йорт, _____ корпус, _________ фатир,

телефон номеры _______________________.

Аерым шәхси счетның иминият номеры______

______________________________________,

Шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәве номеры (шәхси эшмәкәрләр өчен)________________,

электрон почта_________________________

**Муниципаль милектәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә гариза**

Муниципаль милектәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген (кишәрлекләрен) һәм хосусый милектәге җир кишәрлеген (кишәрлекләрен) яңадан бүлү турында килешү төзүегезне сорыйм.

Казан шәһәре Башкарма комитеты карары (территорияне ызанлау проектын яки җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында) реквизитлары: _____елның _______________, № _____.

Ясала торган җир кишәрлегенең кадастр номеры:

1.___________________________________________

2.___________________________________________

3.___________________________________________

Кушымта:

1.___________________________________________

2.___________________________________________

3.___________________________________________

Гаризадагы һәм минем тарафтан тапшырылган документлардагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | ______________ / | ______________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Юридик затлар өчен

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисенә

___________________________________________

*Кемнән:* __________________________________

___________________________________________,

(юридик затның атамасы, оештыру-хокукый формасы)

Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры/
Исәпкә кую сәбәбе коды____________________,
___________________________________________
Төп дәүләт теркәве номеры _________________,
__________________________________ банкында
хисап счеты________________________________
Банкның тәңгәлләштерү коды_______________.
Юридик адрес: индекс______________________,
_______________ шәһәре, _____________________
урамы, __________ йорт, ______________корпус,
телефон номеры ____________________________

**Муниципаль милектәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә гариза**

Муниципаль милектәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген (кишәрлекләрен) һәм хосусый милектәге җир кишәрлеген (кишәрлекләрен) яңадан бүлү турында килешү төзүегезне сорыйм.

Казан шәһәре Башкарма комитеты карары (территорияне ызанлау проектын яки җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында) реквизитлары: ______елның __________________, №_____.

Ясала торган җир кишәрлегенең кадастр номеры:

1._____________________________________________

2._____________________________________________

Кушымта:

1._____________________________________________

2._____________________________________________

Гаризадагы һәм минем тарафтан тапшырылган документлардагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

___________ ___________________ / ______________________________________
(дата) мөһер урыны (имза) (җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
11 номерлы кушымта
(Форма)

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисенә

________________________________________

*Кемнән*: ________________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

______________________________________________________________
(хезмәт атамасы)

буенча муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:______________________________________________________
_____________________________________________________________________.

Дөрес мәгълүматлар: ___________________________________________
_____________________________________________________________________.

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, әлеге карарны:

- электрон документ рәвешендә _________________________ e-mail адресына җибәрүегезне;

- кәгазь чыганакта расланган күчермә рәвешендә __________________________________________ адресы буенча почта аша җибәрүегезне сорыйм.

Әлеге гариза белән гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.

______________ ______________(________________________________)
(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
12 номерлы кушымта
(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү хакында гариза**

_____________________________________________ белән бәйле рәвештә
(дубликат бирү өчен нигез)
муниципаль хезмәт күрсәтү турында _______ елның __________________ ______ номерлы документның дубликатын бирүегезне сорыйм.

Әлеге гаризаны карап тикшерү нәтиҗәсен түбәндәге ысул белән җибәрүегезне сорыйм:

- электрон документ рәвешендә ________________________ e-mail адресына;
- кәгазь чыганакта расланган күчермә рәвешендә __________________________________________ адресы буенча почта аша.

Әлеге гариза белән гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.

______________ ___________(__________________________)
(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Муниципаль милектәге җирләрне
һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
хосусый милектәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
13 номерлы кушымта
(Форма)

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

**Гаризаны карап тикшермичә калдыру хакында гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында ______ елның _______________ _____ номерлы гаризаны ______________________________________ сәбәпле карап тикшермичә калдыруыгызны сорыйм.

Әлеге гаризаны карап тикшерү нәтиҗәсен түбәндәге ысул белән җибәрүегезне сорыйм:

- электрон документ рәвешендә _______________________________________ e-mail адресына;

- кәгазь чыганакта расланган күчермә рәвешендә ____________________________________________ адресы буенча почта аша.

Әлеге гариза белән гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.

_______________ _____________(___________________________)

(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)